КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 12 февраль г.Казань № 95

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2025 ел, 11 сентябрь, 687 нче карары белән расланган «Өстәмә һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2025 ел, 11 сентябрь, 687 нче карары белән расланган «Өстәмә һөнәри белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына, 2.1 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2025 елның 24 мартындагы 266 номерлы боерыгы;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин